**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеменгерского сельского поселения**

422750, Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1
тел. 2-15-68, факс 2-15-68

422756, Атнинский муниципальный район
с.Большой Менгер, ул. Советская, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» ноябрь 2024 ел. № 7

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 17 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 17 ноябрь 2024 ел 10.30 сәгатьтән 11.30 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны — Шеканясь авылы, Татарстан урамы,21 йорт урыны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Шеканясь торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Шеканясь торак пункты халкына массакүләм мәгълумат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Олы Әтнә авыл җирлеге Шеканясь торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә

катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (шеканясь торак пункты чокырын чистарту (үләнне чабу, агачларны, куакларны, үсентеләрне кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шеканясь торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

«РИЗА» «КАРШЫ»

«Сез 2024 елга гражданнар җыены тарафыннан билгеләнгән 40 000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган буаны ремонтлау һәм төзекләндерү чараларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Шеканясь торак пунктының җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Шеканясь авылы, Пионер урамы буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Хакимов

Совет Большеатнинского сельского поселения / Олы Әтнә авыл җирлеге Советы / ИНН 1610000571